**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Поручик авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**22.08. 2025** **№ 182**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең 2019 елның 19 мартындагы 146 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 26 декабрендәге 486-ФЗ номерлы федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2014 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2006 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең 2019 елның 19 мартындагы 146 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең 22.06.2023 ел 111 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 12 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

«6. Территорияне комплекслы үстерү максатларында җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертү таләп ителгән очракта, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары буенча, җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча һәм комплекслы үсешкә ия территорияне планлаштыру документлары проекты буенча гавами тыңлаулар һәм (яисә) иҗтимагый фикер алышулар уздыру рөхсәт ителә.»;

1.2. 5 нче кушымтада «һәм язма рәвештә» сүзләреннән соң «яисә электрон документ рәвешендә» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе** **И.И.Хаджаева**